# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай җирлек Советы

Уразай авылы №127-1 30 гыйнвар 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советы 12.10.2012 №26 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (05.08.2013 №45, от 17.03.2014 №63-1, от 15.08.2014 №82, от 25.08.2017 №62 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Уразай» муниципаль берәмлек Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларының чисталыгына һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында һәм тулаем муниципаль берәмлек территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Уразай» авыл җирлеге

Советы Уразай карар чыгарды:

1. 1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советы карары белән расланган 12.10.2012 ел № _ (05.08.2013 №45, от 17.03.2014 №63-1, от 15.08.2014 №82, от 25.08.2017 №62 карарлар редакциясендә) территорияләрне төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый

территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны карап тотуга юнәлтелгән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге;»

"төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пунктын өстәргә:

«2.10.3.1. Йорт билгеләренә, тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү белән урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш, дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шэрифуллина